КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1015

«Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тибын үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение мөлкәте исемлеген кертергә;

ел саен Учреждение өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга;

60 көн эчендә «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе уставына үзгәрешләр кертергә.

3. Учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законда әлеге максатларга каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, әлеге карарның 2 пунктын үтәгәннән соң 60 көн эчендә әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә Татарстан Республикасының кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр эшләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин